ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КИРОВ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423747, Киров авылы,
Киров урамы 52 йорт.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

СОВЕТ КИРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423747, пос. совхоз им. Кирова,
ул. Кирова, дом 52.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

# РЕШЕНИЕ

8 июль 2020 ел № 13

**Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлегенең кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Актаныш муниципаль районының Киров авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районының Киров авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районының Киров авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 13.09.2007 елнын 7/3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «5) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

2. Актаныш муниципаль районының Киров авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә яңа редакциядә» 07.09.2017 елнын 19 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. Нигезләмәләнең 3.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Киров авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Киров авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Киров авыл җирлеге Башлыгы И.Ф.Гаянов